**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «23» октябреннән №49-379

Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәне раслау турында» 2021елның 30 сентябрендәге 14-107 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-107 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-136 номерлы, 2022 елның 8 апрелендәге 20-161 номерлы, 2023 елның 26 маендагы 34-272 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 38-310 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. . Нигезләмәнең 4.6. статьясының 4.6.3. өлешендә «66 статьяның 12 өлеше белән» сүзләрен «66 статьяның 12 һәм 12.1 өлешләре белән» сүзләренә алмаштырырга:

1.2. Нигезләмәнең 4.9. статьясының 4.9.4. өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.»

1.3. Нигезләмәнең 4.9. статьясын түбәндәге эчтәлектәге 4.9.5. өлеш белән тулыландырырга:

«4.9.5. Кучмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләр бозылу билгеләре ачыкланса, әгәр контрольлек рәвеше турында федераль законда, Татарстан Республикасы законында шундый мөмкинлек күрсәтелгән очракта, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 өлешендәге 1 пунктында каралган

тәртиптә, карар кабул ителергә мөмкин».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Экология, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов